# КЫШЛАУЧЫ КОШЛАР



**Классификациясе буенча проект:**

**-кыска вакытлы, декабрь аенын 3**

**-мәгълүмати;**

**-зурлар һәм мәктәпкәчә яшьтәге төркем балалары,ата-аналар,тәрбиячеләр өчен каралган.**

**Проектның эшчәнлеге;**

**-балаларга кирәкле мәгълүмат җиткерү;**

**-үстерешле мөхит тудыру: төрле кошлар муляжлары күрсәтү,дөрес материал сайлау,матур әдәбияттан кошлар турында белем алу;**

**-шөгыльнең эзлекле планын төзү.**

**Проектның үтәлеше:**

**Сөйләм теле:үз сүзләрең белән дөрес итеп кошлар турында хикәя төзеп сөйли белү;**

**-матур әдәбияттан кошлар турында хикәя,әкиятләр уку,кошларга багышланган шигырьләр уку ,ятлау;**

**Уеннар: “казлар аккошлар”,”кошларны ашат”,”кошлар һәм читлек”,һ.б.**

**Табышмаклар,ребуслар чишү.**

**Продуктив эшчәнлек:кошлар рәсемнәрен зурлар төркемендә өлешчә,мәктәпкә хәзерлек төркемендә бөтенләй ясау;**

**-күмәк сөйләшүләр алып бару каралган.**

**Ата-аналар белән эш:әңгәмәләр,киңәшләр,ярдәм кулы сузу,күмәк эшчәнлек (җимлекләр ясау),кошлар турында викторина тәкъдим итү.**

**Проектның презентациясе:Җимлекләр күргәзмәсе оештыру.**


ЭКОЛОГИК-БЕЛЕМ БИРҮ
ПРОЕКТЫ
Азнакай муниципаль районы, №15нче катнаш төрдәге балалар бакчасы татар
теле тәрбиячесе Шәрипова Илсөяр Илгизәр кызының эш тәҗрибәсеннән
artes.su

## МАКСАТЛАР:

1.Балаларның кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;

2.Кошларны танып-белергә, классификацияләргә өйрәт\;

3.Канатлы дусларыбызга карата сакчыл караш уяту, мәхәббәт тәрбияләү.

.



**Буранлы салкын кышларда**
**Ярдәм итегез кошларга.**

# Чыпчык



***ЧЫПЧЫК,ЧЫКЧЫК-ЧЫК-ЧЫРЫК,***
***Җим сиптем, кил тиз очып!***
***Әй,нәни кошчыклар,***
***Кечкенә чыпчыклар,***
***Ни салкын булып та,***
***Яшисез суыкта.***



**Кызылтүшем оялама,**
**Җим сибәмен бер оя.**
**Балан белән миләшне**
**Ашап бетердек күптән.**





**Безгә азык кирәк дип**
**Сезгә хәбәр китердек.**

Урман чыпчыгы(свиристель).
Кошлар- табигать бизәге,
Сез аларны саклагыз.



*Кырау булсын,*
*Кырпак булсын,*
*Китмәс дустым.*
*Җәен-кышын*
*Салмый сары тунын.*
*(Песнәк)*




*Түшләрендә кояш төсе*
*Аркасында яз төсе.*
*Кышын тәрәзәмә килеп:*
*“Таныйсыңмы?” ди төсле.*




*Песнәк (синица) - песнәкләрне авылда да, шәһәрдә дә очратырга мөмкин. Алар кайры ярыкларында кышлаган бөҗәкләр, орлыклар белән туклана..* Песнәкләр көз ахырында көтү-көтү булып җыелалар.Төрле төстәге матур киемле әллә никадәр песнәк әйтерсең бәйрәмгә әзерләнгән. Элеккерәк заманнарда 12 ноябрьне халыкта "Песнәкләр көне" дип йөрткәннәр. Безнең урманнада, паркларда 7 төрле песнәкне очратырга була. Иң зурсы һәм аерылып торганы – зур песнәк. *Бер пар песнәк кыш буена 40 төп җимеш агачын корткычлардан чистарта, миллионнарча бөҗәкләрне юк итә* Песнәкләр февраль башында сайрый. Алар кыш тәмамланганын хәбәр итә. Көз һәм кыш көннәрендә алар җимлекләргә бик еш килә.




Ябалак төнлә уяна
Үзенә ризык эзли.
Аның үткен,зур күзләре
Хәрбер нәрсәне күзли.
Иртән-иртүк,кояш чыккач,
Ябалак йоклап китә.


Очып бара ябалак,
Оча як-якка карап.
Башта уң якка карый,
Аннан сул якка карый,
Азрак утырып ял итә...
Канатларын җилпенә дә
Яңадан очып китә...
MyShared




*Күгәрченем гөр-гөр-гөр,*
*Җим сиптем менә күр-күр.*




**Күгәрчен тыныч көн күрә**
**Кешеләр белән бергә.**

Саескан ала канат
Җим сибәм кабат-кабат.




Ак кардан киенгән
Бер минут та тик киенгән.





Карга әйтә: Кар – кар!
Күктә кояш бар, бар!!!


А л а   карга






Тукран бөтен агачны
Тук-тук-тук сугып карый,
Көчле  һәм очлы борыны
Шундый зур эшкә ярый



# САЛКЫН КЫШЛАРДА АЛАРГА ЯРДӘМ ИТИК

*Карабүрек (снегирь) - безнең як табигатен бизәп торучы кошларның берсе. Ул яз,җәен урманда яши,ә кышын бакчаларга,паркларга очып килә,агач орлыклары,җиләк-җимеш калдыклары белән туена.*

*Тукран (дятел) агачтагы корткыч бөҗәкләрне юк итә, агачның гомерен саклый. Шуңа күрә аны "урман докторы" дип йөртәләр. Ул, каты койрыгы белән агач кәүсәсенә терәлеп, аңа көчле тырнаклары белән ябыша. Аннары томшыгы белән агачны тук-тук чукып, бөҗәкне эзләп таба һәм теле белән эләктереп ала да ашый. Шулай итеп, үзе дә туклана, урманга да файда китерә. Тукраннар агач куышына оялый. Аларт бер-берләрен тукылдаган тавышларыннан таныйлар.*

*Саескан (сорока) урман аланлыкларында,бакчаларда,басу-кырларда яши. Бөҗәкләр, суалчаннар белән туклана.*

*Күгәрчен ( голубь) – күгәрченнәрнең төрләре бик күп. Без күбрәк күк күгәрченнәрне беләбез. Аның канатлары куксел төстә була. Тәпиләре кып-кызыл.Ул, вак-вак атлап, яңа яуган карда бормалы, кәкре-бөкре эзләр калдырып йөри.Күгәрчен башка кошлардан юлны тиз табуы белән аерылып тора. Моннан күп йөз еллар элек хатларны күгәрченнәр ташыган. Күгәрченнәрнең бу төре почта күгәрчене дип йөртелә. Күгәрчен дуслык һәм тынычлык символына әйләнде.*

















Азык булса,җиңел була
Бар кошларга кышларга!





# Йомгаклау:

Эшләү нәтиҗәсендә шуны ачыкладык. Кошлар безнең ярдәмгә мохтаж.Аларга ярдәм итеп без,кошларны гына саклап калмыйбыз,ә табигатебезне дә кайгыртабыз.Кошлар тикмәгә генә табигать докторлары дип аталмый. Аларның тавышы күңелләрне ял иттерә.

**Шуңа күрә: кошларны саклыйк,яклыйк.Аларга кулдан килгәнчә ярдәм итик.**

Игътибарыгыз
өчен
рәхмәт!!!